| ГЛАВА САКЛОВ-БАШСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ САРМАНОВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ САРМАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ САКЛАУБАШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛАГЫ |
| --- | --- |

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

№ 6 07.11.2023

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Саклаубаш авыл җирлеге Саклаубаш авылында 2024 нче елда гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча халык җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьялары, 18.1 статьясы нигезендә. Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Саклаубаш авыл җирлеге Уставы: нигезендә карар бирәм:

1. Саклаубаш авыл клубы бинасында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын 17 нче ноябрь 2023 нчы ел 10:00 сәгатькә билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга: «Саклаубаш авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган, I төркем инвалидларыннан тыш, 2024 елда үзара салым акчаларын кертүгә, вакытлы хәрби хезмәт үтүче гражданнардан, көндезге уку йортлары студентларыннан һәм алдагы эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны җибәрүгә килешәсезме?:

1) халыкның массакүләм ял итү урыннарын төзеклзү (ягулык материаллары һәм триммер сатып алу)

2) Саклаубаш торак пунктына урам яктырту челтәрләрен ясау

3) Автомобиль юлларын карап тору өчен МТЗ-82.1 махсус техникасын карап тоту (ягулык-майлау материаллары, запчастьләр сатып алу, машина йөртүчегә хезмәт хакы түләү);

4) Халыкара хатын-кызлар көне, Җиңү көне, сабантуй, өлкәннәр көне, Инвалидлар көне, Алга торак пунктында төрле чаралар үткәрү өчен бүләкләр, алу;

«ӘЙЕ» “ЮК".

3. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми

порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) урнаштырырга. («Сарман муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында) һәм «Интернет» мәгълүмат – телекоммуникация челтәрендә, Саклаубаш, Өчөйле Саклау, Алга, Яңа Саклау авылларында урнашкан махсус мәгълүмат стендларында.

4. Әлеге карар ул басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Саклаубаш авыл
җирлеге башлыгы                Л.М.Габидуллина